**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

Ленин пр.,17йорт,Актаныш ав.,423740

Тел.(85552)3-44-22,факс (85552) 3-44-14,E-mail:aktanysh@tatar.ru,www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
30 ноября 2018 г.

КАРАР
№ ПР-296

**2019 елга Актаныш муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының норматив чыгымнарынраслау турында**

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 29.12.2012 ел, № 273 Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының «Актаныш муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрен норматив финанслауны кертү турында» 2007 ел, 11 декабрь, ПР-452 карары нигезендә, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Актаныш муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары һәм гомуми белем бирү интернат мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне карауга 2019 елга беркетелгән норматив чыгымнарны расларга.

2. Актаныш муниципаль районының финанс-бюджет палатасына «2019 елга Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга гражданнарның хокукларын гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 2018 елның 24 сентябрендәге 57-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән һәм әлеге карарның 1 пункты белән расланган мәгариф оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар аның Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль мәсьәләләр буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Л.Ф.Нурлыевага йөкләргә.

Җитәкче И.Ш.Бариев

Расланды
Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе карары белән
30 ноябрь 2018 ел, № ПР-296

**Актаныш муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары һәм гомуми белем бирү интернат мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне тотуга норматив чыгымнар**

| Гомуми белем бирү оешмасының тибы һәм төре | Территориаль дислокация | Бер тәрбияләнүчегә, елына норматив чыгымнар |
|---|---|---|
| Гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернат | авыл җирлеге | 90630 |
| Гомуми белем бирә торган мәктәп-интернат | авыл җирлеге | 139893 |